СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**25 октябрь 2021 ел** **№ 5**

**Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Югары Аты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Югары Аты авылында Югары Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 10 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Югары Аты авылында Югары Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 10 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Кооператив, Мәктәп урамнарында яшәүчеләр;

2нче этап: Комсомол урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясеннән һәм Аты елгасы буйлап агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару;

- Арча-Олы Әтнә төбәк юлы янындагы чишмә өчен материал сатып алу һәм төзекләндерү;

- вак таш сатып алу, җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл катламнарына таш җәю һәм тигезләү;

- амкадор, бульдозер хезмәтләре өчен түләү

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Югары Аты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Утар - Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Югары Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Утар - Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева